ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**27.02.2026**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 676**

Зеленодольск муниципаль районы Зеленодольск шәһәре территориясендә күп фатирлы йортта торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен үзгәртү буенча иң чик индексның күләмен билгеләү турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Күп фатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында, торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен билгеләү турында, шулай ук мондый түләүнең иң чик индексларын билгеләү тәртибен билгеләү турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен билгеләү буенча методик тәкъдимнәрне раслау хакында» 2018 елның 06 апрелендәге 213/пр номерлы боерыгы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Зеленодольск шәһәре территориясендә социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарны яллаучылар өчен, күп фатирлы торак йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар һәм күп фатирлы йортлардагы торак урыннарны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән торак урыннары милекчеләре өчен түләү күләмен үзгәртүнең чик индексын 12,99% ка тигез итеп билгеләргә.

2 Әлеге карарны Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми (http://pravo.tatarstan.ru) порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуын 2026 елның 01 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә таратырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче З.Ф. Хәбибуллин